**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 12 февралендәге 346 номерлы карары**

## Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җеназа эше турында»гы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен, әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә, 2025 елның 1 февраленнән 9165 сум 37 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 13 февралендәге 476 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 февралендәге
346 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**2024 елның 1 февраленнән Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр (табутта җирләү) бәясе**

| **Хезмәт атамасы** | **Хезмәтнең бәясе, сум** |
| --- | --- |
| Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 2988,54 |
| Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка алып бару (3,00 сәгать исәбеннән) | 2054,19 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4122,64 |
| **БАРЛЫГЫ** | **9165,37** |

___________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 февралендәге
346 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**2024 елның 1 февраленнән Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр (кәфенләп җирләү) бәясе**

| Хезмәт атамасы | Хезмәтнең бәясе, сум |
|---|---|
| Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| Кәфенләү | 1774,60 |
| Җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китереп бирү | 805,95 |
| Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка алып бару (3,00 сәгать исәбеннән) | 2054,20 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4530,62 |
| **БАРЛЫГЫ** | **9165,37** |

___________________